ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2020 г. с. Муслюмово № 132

**Мөслим муниципаль районының 2020 елда**
**балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендә 1272 номеры белән кабул ителгән “Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында” карар нигезендә, 2019 елның 17 октябрендә кабул ителгән 924 номерлы карарда кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә 2020 елда балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, мәктәп каникуллары чорында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатыннан Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставының 44 матдәсе нигезендә Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.1 нче кушымта нигезендә Мөслим муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча Ведомствоара комиссия төзү.

2. Расларга:

- Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча Ведомствоара комиссия турында нигезләмә (2 нче кушымта).
- Мөслим муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында нигезләмә (3 нче кушымта).
- 2020 елда «Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагерен ачуга әзерлек буенча чаралар планы (4 нче кушымта).
- Мөслим муниципаль районы яшьләренең 2020 елга ял итү программасы (5 нче кушымта).

3. Мөслим район үзәк хастахансенә тәкъдим итәргә:

- «Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагерен килешү нигезендә квалификацияле медицина кадрлары белән тәэмин итәргә;
- укудан буш вакытта һәм каникул чорында вакытлыча эшкә урнашуны рәсмиләштергәндә бәлигъ булмаган балаларга һәм балалар сәламәтләндерү учреждениеләренә вакытлыча эшкә җибәрелә торган персоналга медицина тикшерүләре оештыру;
- сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә юнәлдерелгән персоналга бушлай флюорография тикшерүен тәэмин итү;

-Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2011 елның 12 апрелендәге 302-н номерлы боерыгы таләпләре нигезендә, Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыруга бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән, ял оештыру эшенә җибәрелә торган персоналны бушлай тикшерү уздыруны тәэмин итү.

4. Мөслим районындагы җаваплылыгы чикләнгән «АК БАРС Мед” филиалына тәкъдим итәргә:

- бәлигъ булмаган балаларны вакытлыча эшкә урнаштыру вакытында медицина тикшерүләре өчен һәм каникул вакытында балаларның ялын оештыру учреждениеләренә вакытлыча эшкә җибәрелгән персоналның тикшерелүен түләүне оештырырга.

5. ТР буенча Роспотребнадзорның Мөслим муниципаль районы буенча Яр Чаллы идарәсенә, Актаныш һәм Мөслим районнары буенча Татарстан Республикасы буенча Яр Чаллы шәһәре Федераль бюджет сәламәтләндерү оешмасы “Гигиена һәм эпидемиология үзәгенә" тәкъдим итәргә:

- барлык типтагы лагерьларның азык-төлек блогы хезмәткәрләренә гигиена буенча укуларны, лагерьнең лаборатор-инструменталь тикшеренүләрен түләүсез нигездә башкарырга.

6. Татарстан Республикасының Россия күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Мөслим районы бүлегенә тәкъдим итәргә:

- әзерлек һәм ял вакытында сәламәтләндерү учреждениеләрендә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне тәэмин итәргә;

- янгын-техник минимум программалары буенча балалар сәламәтләндерү лагерьларының җитәкчеләрен һәм педагогик составын укытуны оештырырга.

7. "Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесе, «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе, Башкарма комитетның яшьләр эшләре бүлеге, гомуми белем бирү мәктәпләре директорларына:

- «Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагерендә, көндезге мәктәп яны лагерьләрендә, көндезге мәктәп яны ял һәм хезмәт лагерьләрендә балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруны тәэмин итәргә;

- авыр тормыш хәлендә калган балаларның, ятим балаларның, кораллы конфликтларда зыян күргән хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләрендәге балаларның, аларга тиңләштерелгән затларның һәм һөнәри эзләү-коткару формированиеләрендә хезмәт куючы коткаручыларның гаиләләрендәге балаларның, бәлигъ булмаган балалар комиссиясендә исәптә торучы, социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның ялын беренче чиратта оештыруны тәэмин итәргә;

- лагерьларда балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре белән берлектә кыска вакытлы өстәмә белем бирү берләшмәләре эшчәнлеген оештырырга;

- «Мәктәптән тыш эшләр үзәге” муниципаль бюджет учреждениесе базасында “Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагеренә, көндезге мәктәп яны лагерьларына эшкә җибәрелүче педагогик кадрларны укытуны тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгына, «Җәй” балалар һәм яшүсмерләрнең сәламәтлекләрен, ялын һәм мәшгульлеген оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә хисап тотарга:

- 2020 елның 1 маена кадәр барлык типтагы лагерьларны ачу графиклары турында мәгълүмат бирү;

- 2020 елның мартыннан декабренә кадәр, өч көнлек срокта оператив мәгълүмат һәм ай саен 25-нә кадәр ял итү һәм сәламәтләндерүне оештыруга бүлеп бирелгән акчаларның суммасы күрсәтелгән мониторинг тапшыру.

- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгына:

- 2020 елның 1 маена кадәр көндезге мәктәп яны лагерьлары һәм көндезге мәктәп яны ял һәм хезмәт лагерьларын ачу графиклары турында мәгълүмат бирү;

- 2020 елның мартыннан декабренә кадәр, өч көнлек срокта оператив мәгълүмат һәм ай саен 25-нә кадәр көндезге мәктәп яны лагерьларында, көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында балаларның ялын оештыру турында мәгълүмат бирү.

8. Башкарма комитетның яшьләр эшләре бүлегенә:

- 2020 елның 1 июненнән 30 августына кадәр балалар һәм яшьләрнең ялын оештырырга;

- “Яшьлек” спорт һәм сәламәтләндерү комплексы базасында спорт мәйданчыклары эшен оештыру;

- “Мизгел” яшьләр үзәге базасында балалар һәм яшьләрнең мәдәни- күңел ачу чараларын үткәрү;

- «Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагерын үстерү һәм матди-техник базасын ныгыту буенча эш алып барырга.

9. Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль бүлегенә тәкъдим итәргә:

- авыр тормыш хәлендә булган балаларның, шул исәптән Татарстанда җан башына уртача кереме яшәү минимумы күләменнән түбән булган гаиләләрдәге балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруны тәэмин итәргә;

- социаль куркыныч хәлдә булган балаларның;

- Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы карамагындагы башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә белем алучы ятим балаларның;

- агымдагы елда дәүләт социаль ярдәме алмаган, озатучысыз да үз-үзенә хезмәт күрсәтә алган инвалид балаларның ялын оештырырга.

10. Мөслим муниципаль районы “Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" дәүләт бюджет учреждениесына тәкъдим итәргә:

- 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге бәлигъ булмаган балаларны укудан буш вакытларында эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга;

- район Башкарма комитеты белән берлектә бәлигъ булмаганнар эшләре буенча комиссия һәм бүлекчәдә исәптә торучы бәлигъ булмаганнарны эшкә урнаштыруны беренче чиратта оештырырга;

- мәгариф идарәсе, яшьләр эшләре бүлеге белән берлектә предприятиеләрдә, оешмаларда каникул вакытында бәлигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырырга.

11. Мөслим муниципаль районы мәдәният бүлегенә:

- «Урман иле " ял һәм сәламәтләндерү лагерендә китапханәләр эшен оештырырга;

-тематик дискотекалар, күңел ачу тамашалары, концертлар оештырырга;

- мәктәп яны лагерьларында, «Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагерендә балалар кинофильмнары һәм мультфильмнар күрсәтүне оештырырга.

12. Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтлеген һәм мәшгульлеген оештыруны финанслау түбәндәге чыганаклардан башкарыла:

- Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

- җирле үзидарә акчасы;

- ата-аналар акчасы;

- гамәлдәге законнарда каралган башка чыганаклар.

13. Барлык типтагы лагерь җитәкчеләренә ата-аналардан җыела торган түләү өлешен Мөслим муниципаль районында балалар ялын оештыруга тотыла торган финанс чыгымнары нормативының 15 проценты күләмендә билгеләүне тәкъдим итәргә.

14. Россия эчке эшләр министрлыгының Мөслим районы буенча бүлегенә тәкъдим итәргә:

- ял итү урынына бару һәм кире кайту маршруты буенча оештырылган балалар төркемнәре хәрәкәте вакытында җәмәгать тәртибен тәэмин итү буенча чаралар күрү;

- «Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагере территориясен тәүлек буе саклауны, җәмәгать тәртибен һәм иминлекне тәэмин итүне оештыру.

15. Предприятие, оешма һәм хуҗалык җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- каникул вакытында бәлигъ булмаган балалар өчен эш урыннары булдырырга.

16. “Минзәлә урманчылыгы” дәүләт бюджет учреждениесының Мөслим участок урманчылыгына тәкъдим итәргә:

- урман территорияләрен тәртипкә китерүдә ял һәм сәламәтләндерү лагере администрациясенә ярдәм итәргә;

- ял һәм сәламәтләндерү лагерена караган 500 метр радиустагы территорияне уңайлы санитар халәткә китерү һәм даими рәвештә санитар чистарту үткәреп торырга.

17. Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениеләре директорларына:

- мәктәп яны лагерьларын, хезмәт һәм ял лагерьларын азык-төлек блогы хезмәткәрләре, шулай ук лагерьлар эшләү чорында кирәкле техник персонал белән тәэмин итәргә;

- республика профильле сменаларын оештырганда «Урман иле» ял һәм сәламәтләндерү лагере эшчәнлеге юнәлеше буенча ярдәм күрсәтергә;

- балаларның тормыш иминлеген һәм сәламәтлеген тәэмин итү, балалар травматизмын, мәктәп каникуллары вакытында юл хәрәкәте иминлеген кисәтү өчен шартлар тудыру, балаларны сәламәтләндерү һәм ял итү оешмаларында янгынга каршы куркынычсызлык таләпләрен үтәүгә, лагерьларны урнаштыруга, карап тотуга һәм эш режимын оештыруга аерым игътибар бирергә.

18. «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте филиалы “Мөслим-информ»: массакүләм мәгълүмат чараларында балалар сәламәтләндерү учреждениеләренең тәрбия, үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту буенча уңай тәҗрибәсен һәм 2020 елда сәламәтләндерү кампаниясен оештыру һәм үткәрүдә иң актуаль проблемаларны яктыртуны тәэмин итәргә.

19. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе начальнигы Р. Т. Демидовны йөкләргә.

**Мөслим муниципаль районы**
**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Р.А.Ильясов**